# Без һәм безнең сәламәтлегебез



## 3нче сыйныф


Татарстан Республикасы
Чүпрәле районы
Марс урта мәктәбе
Башлангыч сыйныф укытучысы
Раимова Резедә Абрик кызы

# Дәреслекнең бу бүлеге безне түбәндәгеләр белән таныштыра:

- Кеше организмының төзелеше нинди, һәм ул ничек эшли;
- Сәламәт булу өчен нәрсә эшләргә кирәк һәм нәрсә эшләргә ярамый.

# "Кеше организмы"

# Кеше организмы



# Органнар системасы

- Йөрәк
- Үпкә
- Ашказаны
- Үңәч
- Эчәклек
- Сидек куыгы
- Бавыр
- Бөер

- **Кеше организмы органнардан тора. Алар үзара килешенеп, бер – берсенә ярашып эшлиләр.**
- **Уртак эш башкаручы органнар органнар системаларын барлыкка китерә.**

# Органнар системасы

- Йөрәк, үпкә, ашказаны – болар органнар. Һәр орган билгеле бер төзелешкә ия һәм билгеле бер эш башкара. Мәсәлән: үпкә ярдәмендә кеше сулый. Үпкә - сулыш органы.
- Үңәч, ашказаны, эчәклек һәм башка кайбер органнар – ашкайнату органнары система-сын; йөрәк һәм кан тамырлары кан йөреше системасын барлыкка китерә.
- Бербөтен организм эшчәнлеге белән нерв системасы идарә итә. Ул – баш миеннән, арка миеннән һәм нервлардан тора.


# Нерв системасы



# Кешенең тәненең төзелеше

- Кеше тәненең төзелешен – **кеше анатомиясе** өйрәнә.
- **Органнар функциясен – кеше физиологиясе дигән фәннәр өйрәнә.**

# Эчке органнар



# *Үзеңне тикшер*

- Кеше органнарына мисаллар китерегез.
- Алар нинди эш башкара?
- Органнар системалары нәрсә ул?
- Организм эшчәнлеге белән нинди органнарның системасы идарә итә?
- Кеше анатомиясе һәм физиологиясе нәрсәне өйрәнә?

# Нәрсә артык?

Йөрәк

Бавыр

Колак

Ашказаны

Сидек куыгы

Авыз

Эчәклек

Үпкә

Бөер

Аяк

Баш мие